ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ЛЕНИНОГОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»

«ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

23.11.2021 г.Лениногорск № 1090

Бюджет керемнәренең баш администраторын раслау турында

1998 елның 31 июлендәге 3145-ФЗ Россия Федерациясе Бюджет кодексының 160.1 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Башкарма комитеты, «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Лениногорск шәһәре, Глазово авыл җирлеге, Зәй-Каратай авыл җирлеге, Зеленая Роща авыл җирлеге, Ивановка авыл җирлеге, Керкәле авыл җирлеге, Кармалка авыл җирлеге, Кирлегәч авыл җирлеге, Куакбаш авыл җирлеге, Мичурин авыл җирлеге, Мөэмин-Каратай авыл җирлеге, Түбән Чыршылы авыл җирлеге, Яңа Иштирәк авыл җирлеге, Яңа Чыршылы авыл җирлеге, Писмән авыл җирлеге, Сарабиккол авыл җирлеге, Иске Иштирәк авыл җирлеге, Иске Куак авыл җирлеге, Иске Шөгер авыл җирлеге, Сугышлы авыл җирлеге, Тимәш авыл җирлеге, Туктар-Урдаласы авыл җирлеге, Урмышлы авыл җирлеге, Федотовка авыл җирлеге, Шөгер авыл җирлеге бюджет керемнәренең баш администраторлары итеп, Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең «Финанс-бюджет палатасы» муниципаль казна учреждениесе һәм Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы муниципаль казна учреждениесен расларга.

2. Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең «Финанс-бюджет палатасы» муниципаль казна учреждениесенә һәм Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы

муниципаль казна учреждениесенә керем чыганаклары кушымта нигезендә беркетергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең «Финанс-бюджет палатасы» муниципаль казна учреждениесе рәисе Р.Х.Хәмидуллинга һәм һәм Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы муниципаль казна учреждениесе рәисе Р.Ә. Солтановага йөкләргә.

4.Әлеге карарны рәсми публикатор - «Лениногорские вести» газетасында бастырырга, Лениногорск муниципаль районының рәсми Интернет-сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштырырга.

Җитәкче З. Г. Михайлова

Р.Х. Хәмидуллин
5-18-25

«Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2021 елның 23 ноябрендәге 1090 номерлы карарына кушымта

Лениногорск муниципаль районы авыл җирлекләренең керем чыганакларының баш администраторы Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең «Финанс-бюджет палатасы» муниципаль казна учреждениесе һәм Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы муниципаль казна учреждениесенә беркетелгән керем чыганаклары исемлеге

| Бүлек коды | Бюджет классификациясе коды | Төркемнәрнең, төркемчәләрнең, статьяларның һәм керемнәрнең ярдәмче статьяларының исеме |
|---|---|---|
| **926** | **Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең «Финанс-бюджет палатасы» муниципаль казна учреждениесе** | |
| 926 | 1 08 04020 01 1000 110 | Җирле үзидарә органнарының нотариаль гамәлләр кылуга Россия Федерациясе закон актлары нигезендә вәкаләтле вазыйфаи затлары тарафыннан нотариаль гамәлләр кылган өчен дәүләт пошлинасы (тиешле түләү (яңадан исәпләү, недоимка һәм бурыч суммасы,шул исәптән гамәлдән чыгарылган) |
| 926 | 1 08 04020 01 4000 110 | Җирле үзидарә органнарының Россия Федерациясе закон актлары нигезендә нотариаль гамәлләр кылуга вәкаләтле вазыйфаи затлары тарафыннан нотариаль гамәлләр кылган өчен дәүләт пошлинасы (башка керемнәр) |
| 926 | 1 13 02065 10 0000 130 | Авыл җирлекләре мөлкәтен эксплуатацияләүгә бәйле чыгымнарны каплау тәртибендә керә торган керемнәр |
| 926 | 1 13 02065 13 0000 130 | Шәһәр җирлекләре мөлкәтен эксплуатацияләүгә бәйле чыгымнарны |

| Бүлек коды | Бюджет классификациясе коды | Төркемнәрнең, төркемчәләрнең, статьяларның һәм керемнәрнең ярдәмче статьяларының исеме |
|---|---|---|
| | | каплау тәртибендә керә торган керемнәр |
| 926 | 1 13 02995 10 0000 130 | Авыл җирлекләре бюджетларының чыгымнарын компенсацияләүдән башка керемнәр |
| 926 | 1 13 02995 13 0000 130 | Шәһәр җирлекләре бюджетларының чыгымнарын компенсацияләүдән башка керемнәр |
| әр | 116 02020 02 0000 140 | Муниципаль хокукый актларны бозган өчен административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе субъектлары законнарында билгеләнгән административ штрафлар |
| 926 | 1 16 07090 10 0000 140 | Авыл җирлегенең муниципаль органы, муниципаль казна учреждениесе алдында бурычларны үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән очракта закон яисә шартнамә нигезендә түләнгән башка штрафлар, неустойкалар, пенялар) |
| 926 | 1 16 07090 13 0000 140 | Шәһәр җирлегенең муниципаль органы, муниципаль казна учреждениесе алдында бурычларны үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән очракта закон яисә шартнамә нигезендә түләнгән башка штрафлар, неустойкалар, пенялар) |
| 926 | 1 16 10100 10 0000 140 | Бюджет акчаларыннан законсыз яисә максатчан файдаланмау нәтиҗәсендә китерелгән зыянны каплауга салына торган акчалата түләтүләр (авыл җирлекләре бюджетлары өлешендә) |
| 926 | 1 16 10100 13 0000 140 | Бюджет акчаларыннан законсыз яисә максатчан файдаланмау нәтиҗәсендә китерелгән зыянны каплауга салына торган акчалата түләтүләр (шәһәр җирлекләре бюджетлары өлешендә) |
| 926 | 1 16 10031 13 0000 140 | Иминият очраклары килеп туган очракта, шәһәр җирлеге бюджеты акчаларын алучылар отышлы сатып алучылар булып чыгыш ясаганда зыянны кайтару |
| 926 | 1 16 10061 10 0000 140 | Авыл җирлегенең муниципаль органы (муниципаль казна учреждениесе) белән муниципаль контракт төзүдән читләшүгә |

| Бүлек коды | Бюджет классификациясе коды | Төркемнәрнең, төркемчәләрнең, статьяларның һәм керемнәрнең ярдәмче статьяларының исеме |
|---|---|---|
| | | китерелгән зыянны каплау максатларында түләүләр, шулай ук дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында Россия Федерациясе законнарын бозган өчен авыл җирлеге бюджетына күчерелергә тиешле башка акчалар (муниципаль юл фонды акчалары исәбеннән финанслана торган муниципаль контракттан тыш) |
| 926 | 1 16 10061 13 0000 140 | Шәһәр җирлегенең муниципаль органы (муниципаль казна учреждениесе) белән муниципаль контракт (муниципаль юл фонды акчалары исәбеннән финанслана торган муниципаль контракттан тыш)төзүдән читләшүгә китерелгән чыгымнарны каплау максатларында түләүләр |
| 926 | 116 10123 01 0131 140 | Авыл җирлегенең муниципаль органы (муниципаль казна учреждениесе) белән муниципаль контракт төзүдән читләшүгә китерелгән зыянны каплау максатларында түләүләр, шулай ук дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында Россия Федерациясе законнарын бозган өчен авыл җирлеге бюджетына күчерелергә тиешле башка акчалар (муниципаль юл фонды акчалары исәбеннән финанслана торган муниципаль контракттан тыш) |
| 926 | 1 17 01050 10 0000 180 | Авыл җирлекләре бюджетларына күчерелә торган ачыкланмаган керемнәр |
| 926 | 1 17 01050 13 0000 180 | Шәһәр җирлекләре бюджетларына күчерелә торган ачыкланмаган керемнәр |
| 926 | 1 17 05050 10 0000 180 | Авыл җирлекләре бюджетларының салым булмаган башка керемнәре |
| 926 | 1 17 05050 13 0000 180 | Шәһәр җирлекләре бюджетларының салым булмаган башка керемнәре |

| Бүлек коды | Бюджет классификациясе коды | Төркемнәрнең, төркемчәләрнең, статьяларның һәм керемнәрнең ярдәмче статьяларының исеме |
|---|---|---|
| 926 | 1 17 14030 10 0000 150 | Авыл җирлекләре бюджетларына күчерелә торган үзара салым акчалары |
| 926 | 2 02 16001 10 0000 150 | Муниципаль районнар бюджетларыннан бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә авыл җирлекләре бюджетларына дотацияләр |
| 926 | 2 02 16001 13 0000 150 | Муниципаль районнар бюджетларыннан бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә шәһәр җирлекләре бюджетларына дотацияләр |
| 926 | 2 02 29900 10 0000 150 | Җирле бюджетлардан авыл җирлекләре бюджетларына субсидияләр |
| 926 | 2 02 29900 13 0000 150 | Җирле бюджетлардан шәһәр җирлекләре бюджетларына субсидияләр |
| 926 | 2 02 35118 10 0000 150 | Җирлекләрнең, муниципаль һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары тарафыннан беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыру өчен авыл җирлекләре бюджетларына субвенцияләр |
| 926 | 2 02 35930 10 0000 150 | Граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу өчен авыл җирлекләре бюджетларына субвенцияләр |
| 926 | 202 45160 10 0000 150 | Башка дәрәҗәдәге хакимият органнары тарафыннан кабул ителгән карарлар нәтиҗәсендә барлыкка килгән өстәмә чыгымнарны компенсацияләү өчен авыл җирлекләре бюджетларына тапшырыла торган бюджетара трансфертлар |
| 926 | 2 02 45160 13 0000 150 | Башка дәрәҗәдәге хакимият органнары тарафыннан кабул ителгән карарлар нәтиҗәсендә барлыкка килгән өстәмә чыгымнарны компенсацияләү өчен шәһәр җирлекләре бюджетларына тапшырыла торган бюджетара трансфертлар |
| 926 | 2 08 05000 10 0000 150 | Артык түләнгән яисә артык түләтелгән салымнарны, җыемнарны һәм башка түләүләрне кире кайтаруны (исәпкә алуны) гамәлгә ашыру өчен, шулай ук мондый кире кайтаруны вакытында башкармаган өчен процентлар һәм артык түләтелгән суммаларга исәпләнгән |

| Бүлек коды | Бюджет классификациясе коды | Төркемнәрнең, төркемчәләрнең, статьяларның һәм керемнәрнең ярдәмче статьяларының исеме |
|---|---|---|
| | | процентлар суммалары авыл җирлекләре бюджетларыннан (җирлекләр бюджетларына) күчерүләр |
| 926 | 2 08 05000 13 0000 150 | Артык түләнгән яисә артык түләтелгән салымнарны, җыемнарны һәм башка түләүләрне кире кайтаруны (исәпкә алуны) гамәлгә ашыру өчен, шулай ук мондый кире кайтаруны вакытында башкармаган өчен процентлар һәм артык түләтелгән суммаларга исәпләнгән процентлар суммалары шәһәр җирлекләре бюджетларыннан (җирлекләр бюджетларына) күчерүләр |
| 926 | 2 18 05010 10 0000 150 | Авыл җирлекләре бюджетларының узган еллардагы субсидияләрнең калган өлешен бюджет учреждениеләре тарафыннан кире кайтарудан керемнәре |
| 926 | 2 18 05010 13 0000 150 | Шәһәр җирлекләре бюджетларының узган еллардагы субсидияләрнең калган өлешен бюджет учреждениеләре тарафыннан кире кайтарудан керемнәре |
| 926 | 2 19 45160 10 0000 150 | Башка дәрәҗәдәге хакимият органнары тарафыннан кабул ителгән карарлар нәтиҗәсендә барлыкка килгән өстәмә чыгымнарны компенсацияләү өчен тапшырыла торган башка бюджетара трансфертларның калдыкларын авыл җирлекләре бюджетларыннан кире кайтару |
| 926 | 2 19 45160 13 0000 150 | Башка дәрәҗәдәге хакимият органнары тарафыннан кабул ителгән карарлар нәтиҗәсендә барлыкка килгән өстәмә чыгымнарны компенсацияләү өчен тапшырыла торган башка бюджетара трансфертларның калдыкларын шәһәр җирлекләре бюджетларыннан кире кайтару |
| 926 | 2 19 60010 10 0000 150 | Максатчан билгеләнеше булган башка субсидияләрнең, субвенцияләрнең һәм башка бюджетара трансфертларның калган калдыкларын авыл җирлекләре |

| Бүлек коды | Бюджет классификациясе коды | Төркемнәрнең, төркемчәләрнең, статьяларның һәм керемнәрнең ярдәмче статьяларының исеме |
|---|---|---|
| | | бюджетларыннан кире кайтару |
| 926 | 2 19 60010 13 0000 150 | Максатчан билгеләнеше булган башка субсидияләрнең, субвенцияләрнең һәм башка бюджетара трансфертларның калган калдыкларын шәһәр җирлекләре бюджетларыннан кире кайтару |
| **937** | **Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы муниципаль казна учреждениесе** | |
| 937 | 1 11 05025 10 0000 120 | Аренда түләве рәвешендә алына торган керемнәр, шулай ук авыл җирлекләре милкендә булган җирләр өчен аренда шартнамәләрен төзүгә хокук сатудан алынган акчалар (муниципаль бюджет һәм автоном учреждениеләрнең җир кишәрлекләреннән тыш) |
| 937 | 1 11 05025 13 0000 120 | Аренда түләве рәвешендә алына торган керемнәр, шулай ук шәһәр җирлекләре милкендә булган җирләр өчен аренда шартнамәләрен төзүгә хокук сатудан алынган акчалар (муниципаль бюджет һәм автоном учреждениеләрнең җир кишәрлекләреннән тыш) |
| 937 | 1 11 05035 10 0000 120 | Авыл җирлекләре белән идарә итү органнарының оператив идарәсендәге һәм алар төзегән учреждениеләрне (муниципаль бюджет һәм автоном учреждениеләр мөлкәтеннән тыш)арендага бирүдән кергән керемнәр |
| 937 | 1 11 05035 13 0000 120 | Шәһәр җирлекләре белән идарә итү органнарының оператив идарәсендәге һәм алар төзегән учреждениеләрне (муниципаль бюджет һәм автоном учреждениеләр мөлкәтеннән тыш) арендага бирүдән кергән керемнәр |
| 937 | 1 11 05075 10 0000 120 | Авыл җирлекләре казнасын тәшкил иткән мөлкәтне арендага бирүдән кергән керемнәр (җир кишәрлекләреннән тыш) |
| 937 | 1 11 05075 13 0000 120 | Шәһәр җирлекләре казнасын тәшкил иткән мөлкәтне арендага бирүдән кергән керемнәр (җир кишәрлекләреннән тыш) |

| Бүлек коды | Бюджет классификациясе коды | Төркемнәрнең, төркемчәләрнең, статьяларның һәм керемнәрнең ярдәмче статьяларының исеме |
|---|---|---|
| 937 | 1 11 07015 10 0000 120 | Авыл җирлекләре төзегән муниципаль унитар предприятиеләрнең салымнарны һәм мәҗбүри башка түләүләрне керткәннән соң кала торган керем өлешен күчерүдән керемнәр |
| 937 | 1 11 07015 13 0000 120 | Шәһәр җирлекләре төзегән муниципаль унитар предприятиеләрнең салымнарны һәм мәҗбүри башка түләүләрне керткәннән соң кала торган керем өлешен күчерүдән керемнәр |
| 937 | 1 11 08050 10 0000 120 | Авыл җирлекләре милкендәге мөлкәтне (муниципаль бюджет һәм автоном учреждениеләр мөлкәтеннән, шулай ук муниципаль унитар предприятиеләр, шул исәптән казна предприятиеләре мөлкәтеннән тыш) залогка, ышанычлы идарәгә тапшырудан алына торган акчалар |
| 937 | 1 11 08050 13 0000 120 | Шәһәр җирлекләре милкендәге мөлкәтне (муниципаль бюджет һәм автоном учреждениеләр мөлкәтеннән, шулай ук муниципаль унитар предприятиеләр, шул исәптән казна предприятиеләре мөлкәтеннән тыш) залогка, ышанычлы идарәгә тапшырудан алына торган акчалар |
| 937 | 1 11 09080 13 0000 120 | Стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыру һәм эксплуатацияләүгә, шәһәр җирлекләре милкендә булган җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә реклама конструкцияләрен урнаштыру һәм эксплуатацияләүгә хокук бирү килешүе кысаларында кергән түләү |
| 937 | 1 14 02052 10 0000 410 | Авыл җирлекләренең идарә органнары карамагындагы учреждениеләрнең оператив идарәсендәге мөлкәтне (муниципаль бюджет һәм автоном учреждениеләр мөлкәтеннән тыш) реализацияләүдән керемнәр, күрсәтелгән мөлкәт буенча төп чараларны гамәлгә ашыру өлешендә |

| Бүлек коды | Бюджет классификациясе коды | Төркемнәрнең, төркемчәләрнең, статьяларның һәм керемнәрнең ярдәмче статьяларының исеме |
|---|---|---|
| 937 | 1 14 02052 13 0000 410 | Шәһәр җирлекләренең идарә органнары карамагындагы учреждениеләрнең оператив идарәсендәге мөлкәтне (муниципаль бюджет һәм автоном учреждениеләр мөлкәтеннән тыш) реализацияләүдән керемнәр, күрсәтелгән мөлкәт буенча төп чараларны гамәлгә ашыру өлешендә |
| 937 | 1 14 02052 10 0000 440 | Авыл җирлекләре белән идарә итү органнары карамагында булган учреждениеләрнең оператив идарәсендәге мөлкәтне (муниципаль бюджет һәм автоном учреждениеләр мөлкәтеннән тыш) сатудан алынган керемнәр, күрсәтелгән мөлкәт буенча матди запасларны гамәлгә ашыру өлешендә |
| 937 | 1 14 02052 13 0000 440 | Шәһәр җирлекләре белән идарә итү органнары карамагында булган учреждениеләрнең оператив идарәсендәге мөлкәтне (муниципаль бюджет һәм автоном учреждениеләр мөлкәтеннән тыш) сатудан алынган керемнәр күрсәтелгән мөлкәт буенча матди запасларны гамәлгә ашыру өлешендә |
| 937 | 1 14 02053 10 0000 410 | Авыл җирлекләре милкендәге бүтән мөлкәтне (муниципаль бюджет һәм автоном учреждениеләр, шулай ук муниципаль унитар предприятиеләр, шул исәптән казна предприятиеләре мөлкәтеннән тыш) сатудан алынган керемнәр, күрсәтелгән мөлкәт буенча төп чараларны гамәлгә ашыру өлешендә |
| 937 | 1 14 02053 13 0000 410 | Шәһәр җирлекләре милкендәге бүтән мөлкәтне (муниципаль бюджет һәм автоном учреждениеләр, шулай ук муниципаль унитар предприятиеләр, шул исәптән казна предприятиеләре мөлкәтеннән тыш) сатудан алынган керемнәр, күрсәтелгән мөлкәт буенча төп |

| Бүлек коды | Бюджет классификациясе коды | Төркемнәрнең, төркемчәләрнең, статьяларның һәм керемнәрнең ярдәмче статьяларының исеме |
|---|---|---|
| | | чараларны гамәлгә ашыру өлешендә |
| 937 | 1 14 02053 10 0000 440 | Авыл җирлекләре милкендә булган бүтән мөлкәтне (муниципаль бюджет һәм автоном учреждениеләр, шулай ук муниципаль унитар предприятиеләр, шул исәптән казна предприятиеләре мөлкәтеннән тыш) сатудан алынган керемнәр, күрсәтелгән мөлкәт буенча матди запасларны гамәлгә ашыру өлешендә |
| 937 | 1 14 02053 13 0000 440 | Шәһәре җирлекләре милкендә булган бүтән мөлкәтне (муниципаль бюджет һәм автоном учреждениеләр, шулай ук муниципаль унитар предприятиеләр, шул исәптән казна предприятиеләре мөлкәтеннән тыш) сатудан алынган керемнәр, күрсәтелгән мөлкәт буенча матди запасларны гамәлгә ашыру өлешендә |
| 937 | 1 14 06025 10 0000 430 | Авыл җирлекләре милкендәге җир кишәрлекләрен сатудан керемнәр (муниципаль бюджет һәм автоном учреждениеләрдән тыш) |
| 937 | 1 17 01050 10 0000 180 | Авыл җирлекләре бюджетларына күчерелә торган ачыкланмаган керемнәр |
| 937 | 1 17 01050 13 0000 180 | Шәһәр җирлекләре бюджетларына күчерелә торган ачыкланмаган керемнәр |